ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 036 от «25» 02 2021 г.

Муниципаль район Башлыгының
2016 елның 20 декабрендәге 129 нчы
карары белән расланган Мамадыш
муниципаль районының «Өмет» («Надежда»)
балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приюты
дәүләт казна учреждениесенә ярдәм
күрсәтү мәсьәләләре буенча Попечительлек
(иҗтимагый) Советы турындагы Нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгының 1998 елның 29 октябрендәге № 44 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тибын үзгәртү юлы белән Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт учреждениеләрен (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют) төзү турында» 2014 елның 12 ноябрендәге 862 нче карары), Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 9 декабрендәге « Мамадыш районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Өмет «социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе Уставын раслау турында» 681 нче боерыгы нигезендә, авыр тормыш хәлендә калган балигъ булмаганнарны социаль яклау мәсьәләләрен хәл итүдә ярдәм күрсәтү максатында, к а р а р б и р ә м:

1. Муниципаль район Башлыгының 2016 елның 20 декабрендәге 129 нчы карары белән расланган Мамадыш муниципаль районының «Өмет» («Надежда») балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приюты дәүләт казна учреждениесенә ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча Попечительлек (иҗтимагый) Советы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 3.12 пункт, 1п.пунктында «утырышны алып баручы» сүзләреннән соң «утырыш үткәрелгән көнне» сүзләрен өстәргә;
- Нигезләмәнең 4.7 пункты 1п.п. түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Попечительләр советы әгъзасы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла».

000044

2. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе И. М. Дәрҗемановка йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы А.П. Иванов